**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«11» ноябрь, 2020 ел Түбән Суык-Су № 10

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Крәшен Маҗын авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Крәшен Маҗын авылында 2020 елның 23 ноябренә 13.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Крәшен Маҗын авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юлларны ремонтлау, вак таш сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Крәшен Маҗын авылы, Үзәк урам, 18 йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә .

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы Ф.Г.Ихсанов